**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКА-СЫ АКТАНЫШ МУНИЦИ-ПАЛЬ РАЙОНЫ ЧАЛМАНАРАТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423752, Чалманарат авылы, Узэк урамы,
2 нче йорт. Тел.5-32-25.

**СОВЕТ ЧАЛМАНАРАТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АК-ТАНЫШСКОГО МУНИЦИ-ПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕС-ПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423752,село Актаныш, улица Цен-тральная,
дом 2. Тел.5-32-25.

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**№2** **19.01.2026**

Актаныш муниципаль районы Чалманарат_ авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 24 маендагы 9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 28.11.2025 ел, № 425-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының “Чалманарат авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Чалманарат авыл җирлеге советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы Чалманарат авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 24 маендагы 9 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 пунктның 5 пунктчасындагы 2 абзацта «проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төгәлләнмәгән төзелеш объектларыннан тыш» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүматы порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә урнаштырырга.

Актаныш муниципаль районы
Чалманарат авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе К.С.Ахметов